Мәкаләдә татар телевидениесе тарихы материаллары системалаштырыла. Тикшеренү материаллары булып, татар режиссёрлары Гали Хөсәенов, Ринат Сакаев, Әхтәм Зарипов, Идмас Үтәгәнов, Гөлсем Беляловалар, тарафыннан иҗат ителгән телевизион спектакльләр, тамашачыларның күзәтүләре һәм хатлары тора. 1970–1990 елларда татар телендәге телеспектакльләрнең һәм телефильмнарның татар мәдәниятен популярлаштырудагы нәтиҗәле форма булганлыгы ачыклана. Телетеатр тарихы тамашачылар белән Казан телестудиясенең әдәби һәм драматик тапшырулар редакторлары арасындагы хатларда үзенчәлекле чагылыш таба.

**Төп төшенчәләр:** татар мәдәнияте, татар телевидениесе, татар театры, телеспектакль, телефильм, укучы хатлары

---

[1] Режиссёр Әхтәм Зариповның шәхси архив материалларының анализы М.М. Хәбетдинова тарафыннан башкарылды, Россия һәм татар телетеатры тарихын өйрәнү материалларын Г. Г. Аксой гомумиләштерде.

## Кереш

Шунысы кызганыч, төбәк телевидениесе тарихы галимнәр тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Тематика буенча киң катлам укучыларга тәкъдим ителә торган китапларның күпчелеген юбилей басмалары тәшкил итә һәм белешмә мәгълүматлар бирү белән чикләнә. ([1], [2]). Фәнни хезмәтләр арасында Е. П. Алексеева [3], [4], А.Т. Галимҗанова [5], Р.В. Даутова [6], [7], [8], [9] хезмәтләрен аерым билгеләргә була.

Энтузиастлар тырышлыгы белән туган Казан телевидение үзэге рәсми рәвештә 1959 елның 6 ноябрендә ачыла. Мәскәү-Свердловск радиореле линиясе төзелеше тәмамлангач, 1962 елның 16 мартында казанлылар Мәскәүдән күрсәтелгән тапшыруны карау мөмкинлегенә ия була. Яңа линияләр төзелгән саен телевидение ТАССР районнарына да үтеп керә башлый. 1970 еллар башына телетапшыруларны республиканың 80 процент территориясендә карап булган [8].

Телевидение үсеше белән берлектә телевизион спектакль / телеспектакль жанры да барлыкка килә. СССРда беренче телевизион спектакль 1938 елда күрсәтелә, әмма ләкин ул вакытта видеоязмалар тәҗрибәсе практикада кулланылмау сәбәпле, телевизион спектакльләр, театр спектакльләре кебек үк, 50 нче еллар башына кадәр турыдан-туры эфирда уйналган (Т-рак кр.: [10]). «Дөреслек – яхшы, ә бәхет тагын да яхшырак» спектакле (1951) «тере» трансляциядә түгел, ә тасмага яздырып уйналган беренче театраль спектакль буларак билгеле. Б. Н. Коноплева билгеләвенчә, телеспектакльләрне кинорегистраторлар ярдәмендә кинотасмага яздыру 1950 нче еллар ахырында гына мөмкин була [11, 180 б.] Нәкъ шушы чорда – «җепшеклек» елларында телевизион театр туа.

Безнең тикшеренүнең яңалыгы татар телевизион театр тарихы буенча мәгълүматларны беренче тапкыр системага салу омтылышын ясауда.

## Материаллар һәм ысуллар

Мәкаләнең максаты – тарихи-типологик ысул ярдәмендә XX гасырның икенче яртысында татар театр сәнгатенең үзенчәлекле формаларының – фильм-спектакльнең һәм динамикадагы телеспектакльнең үсешен татар мәдәнияте контекстында тикшерү; үсеш факторларын ачыклау; әлеге театраль феноменнарның тарихи һәм социомәдәни үзенчәлекләрен барлау.

Тикшеренүнең материалы булып, татар режиссёрлары Гали Хөсәенов, Ринат Сакаев, Әхтәм Зарипов, Идмас Үтәгәнов куйган телеспектакльләр; телетамашачыларның рецензияләре һәм хатлары тора.

## Фикер алышу

Г. П. Сидорова билгеләвенчә, «фильм-спектакльләр һәм телеспектакльләр 1950 нче елларда телевидениенең уңышлы үсеше нәтиҗәсе буларак барлыкка килә». СССРда беренче фильм-спектакльләр 1950 елларда телевидение һәм кинотеатрларда күрсәтү өчен төшерелә башлый. Алар төрле театрлардан актерлар чакырылып, студиядә куела. Күп камералы юл белән кинотасмага телеспектакльләр төшерү өчен театраль һәм телевизион режиссерлар чакырыла. Г. П. Сидорова «фильм-спектакльләр төшерүгә кызыксыну арту массакүләм мәгълүмат чараларының техник үсеше белән генә түгел, ә 1950 елларда уен киносы кытлыгы белән дә бәйле» дип саный. [12, 214–215 б.]. Шушы ук елларда телеспектакль жанрының үзенчәлеге турында беренче тикшеренүләр барлыкка килә [13], [14].

Театр тәнкыйтьчесе Н. Жегин телеспектакльнең сәнгати үзенчәлеге турында түбәндәге фикерен әйтә: «Телевизорның бәләкәй экранында актерның таланты, аның берни белән дә аңлатып булмый торган башка кеше күзеннән карау, аныңча уйлау, ишетү, хис итү... кыскасы, башка кеше тормышы белән яшәү сәләте башка беркайда да булмаганча ачыла.

Театрда зур план юк бит, ул зур аудитория белән аралашуга йөз тота. Анда, ни әйтсәң дә, «шартлылык иероглифы» бар. Анда һәрбер хис аермачык күренә, мизансценаларда, хәрәкәтләрдә чагылыш таба... Анда хиснең үзен рәвеше белән алыштырып була. Ә тамашачы шул рәвешне күреп, таныш кодлар аша геройларның халәтен һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрне таный, төшенә.

Телеспектакль аның өзлексез хәрәкәте белән, зур планнарның муллыгы белән театр һәм киноның шартлылыгыннан мәхрүм – бернинди алдау, ясалмалылык юк, барысы да чын, ихлас. Кеше йөзе, кеше күзләре...

Әгәр дә без сәхнәдә еш кына нәтиҗәне күрәбез һәм ишетәбез икән, телеэкраннарда актёрның дәшмәвеннән, аның партнёры сүзләренә мөнәсәбәтеннән, аның

реакциясеннән, бәясеннән зур ләззәт кичерә алабыз.

Чын телеспектакльдә тасмага төшерүнең характеры, объекты пьесаның мәгънәсен, образларның асылын ачарга ярдәм итә» [15].

Татар телеспектакльләренең чишмә башында режиссер Гали Хөсәенов тора (1919–2001). 1952–1969 һәм 1972–1975 елларда ул Татар радиосы мөхәррире, режиссёр, Казан телевидение студиясенең баш режиссёры булып эшли. Г. Хөсәенов телевидениегә радиоспектакльләр әзерләү буенча зур тәҗрибә туплап килә. Әле балалар өчен тапшырулар режиссеры булып эшләгәндә, ул үз сценарие буенча «Җир» дигән спектакль куя. Анда өлкәннәр белән бергә балалар да катнаша. Спектакль эшләнеше, монтажы белән, музыкаль бизәлеше ягыннан кыска хронометражлы кинофильм кебек карала иде.

Студиягә баш режиссёр булып күчкәч, Г. Хөсәеновның колачы киңәя. Мәскәүнең Щепкин исемендәге училищесын тәмамлап кайткан Туфан Миңнуллин сценарийлар язарга алына. Ике иҗатчы хезмәте нәтиҗәсендә күп серияле телевизион спектакльләр дөнья күрә. Г. Хөсәеновның иң зур эшләре арасында «Анам кыры» (1965) (Чыңгыз Айтматовның шул исемдәге повесте буенча), «Муса» (1966) (Шәйхи Маннурның шул исемдәге романы буенча, 5 серия), «Казакъ кызы» (Г. Ибраһимовның танылган романы мотивлары буенча), «Ак чәчәкләр» (Г. Әпсәләмовның шул исемдәге романы буенча) әсәрләре бар. Иң беренче телеспектакльләр турыдан-туры уйнала. Ул тавышка, телеспектакльләрнең музыкаль бизәлешенә зур игътибар бирә. Аның җиңел кулыннан студиядә кадр эчендәге монтаж – гомумидән зур планга күчү, планнарга наложение ясау, камера белән йөрү кебек режиссёрлык алымнары кулланыла башлый.

Татар телетеатры тарихын режиссер Ринат Сакаевтан башка күз алдына китерү мөмкин түгел (1928–1995). Ул Казан телевидениесендә 13 ел эшли. Аның хезмәттәше, режиссёр ярдәмчесе Л. К. Гущина ул чорны болай дип искә ала: «Ринат Сәет улы белән мин 1968 елда чакыру буенча Казан телестудиясенә режиссёр ярдәмчесе булып эшләргә килгәч таныштым...

Ул чагында бары тик туры эфирда гына эшли идек, аны «эфирга тереләй чыгу» дип атый идек. Яңадан төшерү, монтажлау, яңадан яздыру мөмкин түгел. Шулай да бик күп яктырткыч әсбаплар, махсус кешеләр авыр чыбыкларын күтәреп йөри торган зур телевизион камералар белән шыгрым тулы бәләкәй студиядә даими рәвештә драматик спектакльләр, музыкаль-шигъри композицияләр <…> куела иде, шуннан ук бик күп номерлары булган бәйрәм концертлары да тапшырыла иде. Казанның һәм бирегә гастрольләргә килгән театрларның иң яхшы спектакльләрен трансляциялибез, студиянең әдәби-драма редакциясе дә үзенең спектакльләрен куя. Минемчә, студиянең сәнгати югары дәрәҗәдәге программаларын булдыру буенча мондый сәясәте баш режиссерның казанышы иде» [16, 270–271 б.].

Р. Сакаевның «Беренче театр» телефильмы (1961) татар телевидениесенең «хәзинә»се санала. Анда татар театрының легендага әверелгән актерлары катнаша: Нәҗип Гайнуллин, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Ирек Баһманов, Вера Минкина, Равил Шәрәфиев, Фирдәвес Әхтәмова, Наил Дунаев. Фильмны тамашачылар бүген дә яратып карый.

Г. Р. Сакаева әйтүенчә, Р. Сакаев үзенең бөтен телевизион спектакльләренә сценарийларны үзе язган, аларны рус һәм татар телләренә дә үзе тәрҗемә иткән: «Шомырт чәчәкләре», «Ленинга йөз белән», «Кайтаваз булып музыка яңгырар», «Раифада обелиск», «Туй»» [16, 271 б.]. Р. Сакаев Әнәс Хәсәновның «Тылсымлы яулык» сценариен уңышлы итеп экраннарга чыгара.

Әлегә кадәр режиссёр Әхтәм Зариповның татар телетеатры тарихына керткән өлеше лаеклы бәһасен алмаган, гәрчә аның катнашлыгында төшерелгән телеспектакльләр һәм телефильмнарның исемлеге дүрт дистәгә җитсә дә (1 нче кушымтаны карагыз). Моннан тыш, ул республикабызның күренекле кешеләре турында йөзләрчә очерклар төшергән. Режиссёр сыйфатында Казанның телевидение студиясенә Әхтәм Зарипов 1972 елда килә. 1987–1992 елларда ул баш режиссёр була.

«1968 елдан 1970 елга кадәр әдәби-драматик редакция эфирга 15 телеспектакль әзерләп чыгарды. Театрлар бер сезонга 6-7 спектакль чыгарганны искә алганда, бу аз түгел», – дип чыгыш ясады ТАССР Язучылар берлегенең партия җыелышына махсус чакырылган Казан телестудиясенең ул вакыттагы сәнгать тапшырулары баш мөхәррире А. Сафиуллина» [17].

Ә. Зариповның игътибары Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Шәриф Хөсәенов, Ибраһим Нуруллин,

Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Әхәт Гаффар, Ринат Мөхәммәдиев, Салих Баттал, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Әхсән Баян, Атилла Расих, Тәлгат Галиуллин, Шамил Рәкыйпов, Мәдинә Маликова кебек язучыларның иҗатларына төшә. Журналист Миләүшә Галиуллина билгеләвенчә, Ә. Зарипов сценарийларны эшләгәндә, һәрвакыт иҗади якын килә, әсәргә карата үз карашын белдерергә омтыла [18, 13 б.].

Архив материалларыннан күренгәнчә, телеспектакльләрнең сценарийлары цензура экспертизасыннан тыш, иҗади яктан рецензияләнә дә. Мәсәлән, Ә. Зариповның архивында Әхсән Баянның «Тау ягы повесте» әсәренең сценариена карата драматург Туфан Миңнуллин язган рецензия саклана. Анда рецензент телеспектакльнең сценарий авторына һәм режиссёрына авторның лирик чигенешләрен сакларга киңәш итә. Т. Миңнуллин, тулаем алганда, сценарийдан канәгать булуын әйтә: “Повесть миңа ошый... Сценарийда да бәйләнерлек урын таба алмадым. Автор фикерен сценарий авторы түкми-чәчми саклап, әсәрне телевидение теленә күчерә алган, минемчә. Дөнья күрергә язсын» [19].

1978 елның сентябрендә Әхсән Баянның «Тау ягы повесте» әсәре мотивлары буенча төшерелгән «Йолдызлар җитә һәркемгә» телефильмы СССРның яңа Конституциясенең берьеллыгына багышлап, Кемерово шәһәрендә уздырылган Бөтенсоюз телефильмнар фестивалендә җиңүче була. Телефильмны төшерүчеләр «Иң яхшы режиссёр эше» (Әхтәм Зарипов), «Иң яхшы хатын-кыз ролен башкаручы» (Фирдәвес Хәйруллина), «Иң яхшы замандаш образы» (Илдус Әхмәтҗанов) бүләкләрен алып кайта.

Режиссёрның иҗади биографиясендә иң зур сәхифәләрнең берсе аның Тукай темасы буенча эшләре була. Беренче тулы метражлы фильмны ул 1973 елда тамашачы хөкеменә чыгара. «Яз сулышы»ндагы Г. Тукай ролен Илдус Әхмәтҗанов башкара. Ул аның язмышына да йогынты ясый: «Спектакльдән соң икенче көнне Казан шәһәре мине Тукайның үзен каршылагандай каршылады. Шул көннән соң, мин милләтнең үз шагыйренә карата булган ихлас мәхәббәтен тоеп, Тукайны гомерлеккә үз иттем. Мин хәзер Тукайсыз яши алмыйм. Ул миндә, ул – минеке. Без бергә – гомергә» [20].

Аннан соң Ә. Зарипов тамашачыларга «Тукай – Петербургта» дигән телеспектакль бүләк итә, ул И. Нуруллинның шул исемдәге драмасы мотивлары буенча төшерелә [21]. Г. Тукай ролен Наил Дунаев башкара. Әлеге телеспектакльне тамашачылар яратып кабул итсә дә, әдәбият белгече Г. Тукай образының эшләнешенә карата тәнкыйть сүзләрен белдерә. И. Нуруллин Ә. Зариповны шагыйрьнең рухи дөньясын, аның мәгърифәтчелек идеалларына тугрылыгын, табигатенең максатчанлыгын сурәтләүгә җитәрлек игътибар бирмәүдә, бөек шагыйрьнең тирә-як мохитен тасвирлау белән артык мавыгуда гаепли. Әдәбият белгече режиссёрның игътибарына ике китап тәкъдим итә: И. Нуруллинның Г. Тукай турындагы хикәяләр җыентыгын (1971) [22] һәм З. А. Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» (1971) [23].

1985 елда Ә. Зарипов янә шагыйрь образына әйләнеп кайта. Язучы С. Хәкимнең сценарийга карата профессиональ рецензиясе игътибарга лаек: «Әхтәм Зарипов Тукай турында моңа хәтле билгеле булган тарихи факт, эпизод, вакыйгаларга, шагыйрьнең биографиясенә, иҗатына таянган. Механик рәвештә төзеп чыкмаган, Тукайның шагыйрь буларак бөеклеген ачу йөзеннән, эчке драмасы буенча барган. Тукайның драматик бөек тормышы күз алдыннан уза.

Әсәрдә кемнәр? Күбесе безгә таныш шәхесләр: Тукай үзе, Сәгыйть Рәмиев, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Сүнчәләй, Зәйтүнә, Кәбир Бәкер һәм Муса Бигиевлар... Татар укучысына билгеле образлар. Бу тамашачыга тизрәк барып җитәчәк.

Уңышы нидә? Күп нәрсә таныш булуга карамастан, ялыкмый укыдым. Укыла торган итеп язган автор. Фактларны бәйли торган фикерләр ышандыра. Бәйләнешләр табигый» [24].

С. Хәким Ә. Зариповка «Тукай белән Зәйтүнә», «Тукай белән Гафури» эпизодларының концепциясен кабаттан карарга, шулай ук шагыйрьнең артык озын шигъри текстларыннан баш тартырга киңәш итә.

Татар интеллигенциясе бу фильмны язмыш бүләге итеп кабул итә. Төп рольне башкарган Фирдәвес Җәлиловка карата бик күп мактау сүзләре әйтелә. Мәсәлән, Казан университетын тәмамлаган һәм Украинада яшәүче Ф. И. Гафурова үзенең хатында тамашачыларга «Тукайны тагын да ныграк яраттырганы, аның дошманнарына карата тагын да ныграк нәфрәтләндергәне өчен» актёрга рәхмәтләрен җиткерә. Ул аеруча персонажларның сөйләм теленә соклану белдерә: «Ә теле! Күптән инде

татар телевидениесендә чиста әдәби, халыкның җорлыгы белән катнашкан сөйләм телен ишеткән юк иде!» [25].

Казанда яшәгән Сәит һәм Бикә Шәкүровларның да фикере безгә бик кызык тоелды: «Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына йөз ел тулу уңае белән Татарстан телестудиясе «Тукай» исемле күпсерияле телефильм күрсәтте. Шундый зур тантана көннәрендә без – Тукай белән телебез ачылган буын, телестудиянең бу хезмәтен үзебез өчен зур бүләк итеп кабул иттек. Чыннан да, студиянең иҗат коллективы күп көч куеп, гаять дәрәҗәдә кирәкле эш эшләгән һәм әйтергә кирәк, бу мактаулы эшне уңышлы башкарып чыккан. Фильм зур кызыксыну белән карала. Сюжеты оста корылган серияләрне көтеп аласың. Тукай биографиясенең, Тукай эшчәнлегенең яңа яклары ачылган. Биредә Тукай шагыйрь генә түгел, күпкырлы, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе итеп бирелгән. Фильмны караганда, Тукайга табынучы – без картлар гына түгел, безнең балаларыбыз да сокланып, горурланып утырдылар. Менә нинди шәхесләребез дә булган икән бит безнең!» [26].

Тамашачыларның телефильмны үзләренчә анализлап каравы да сокландыра. Мәсәлән, Габдерәшит Туктаров телеспектакльнең 3 сериясенә карата язган «Әй ташкала-башкала» дигән язмасында Тукай образын эшләгәндә, фактик ялгышлыкларга да игътибар итә: «Экранда күрсәтелгән Тукайның кеше алдында шигырь укуы, гомумән, акланмый. Моның мең сәбәбе бар. Иң беренчесе – Тукай кеше алдында шигырь сөйләмәгән. Алар басылган. (Гомерендә бер мәртәбә «Сәйяр» труппасына кушылып, шигырь укуын иң зур хаталарының берсе итеп санаган). Гадәттә, ул шигыренең 2-3 юлын җырлап, дөресрәге, шыңшып йөргән. Яки «Кәкре койрыклар! – Кая Башны җитү» дигән кебек берәр юл яисә Коръәннән берәр аять укып куя торган булган» [27].

Х. Кумысников Т. Миңнуллинның шул исемдәге пьесасы буенча төшерелгән ике серияле «Без китәбез, сез каласыз» (1996) телефильмына карата язган язмасында Ә. Зариповның татар аксөякләре Хәсән белән Якуб Акчуриннарның образларын тудырганда, карикатура эстетикасыннан баш тартуын билгели. Бу исә режиссёрга татарларның эшлекле элитасы вәкилләренең асыл образларын тудыру мөмкинлеген биргән. Шагыйранә атмосфера тудыруга хезмәт итә торган табигать картиналары аеруча соклану хисләре белән искә алына. Шагыйрьнең табигать белән берлеген ассызыклау өчен Ә. Зарипов контраст алымын оста куллана: сәүдәгәр утарындагы тормыш рәвешенең ыгы-зыгысы гүзәл манзаралы табигать күренешләре җирлегендә аеруча ачык чагыла [28].

Үзгәртеп кору елларында Ә. Зарипов Гариф Ахунов, Ризван Хәмид, Әхәт Гаффар белән берлектә «Тукай» берләшмәсендә «Каргышлы балачак» (7 серия) (1996) фильмын эшли. Тюрколог Рифкат Әхмәтьянов үзенең рецензиясендә Ә. Зариповның бөек Г. Тукайның балачагы картинасын тудырганда, кыюлыгын билгели, чөнки галимнәрдә бу турыда өзек-өзек мәгълүматлар гына бар. Тюрколог фикеренчә, режиссёр дин әһелләре образларын эшләгәндә, стереотипларны җимерә: «Моңа кадәр мулла-хәзрәт халкын фанатикларча үз диннәрен үтәүче, үзләре дә сукырларча һәр нәрсәгә ышанучылар дип кенә укып, карап, күреп тәрбияләнгән буын. Баксаң-күрсәң, аларның да үз драмалары, үз кичерешләре, үз шатлыклары бар икән». [29, 14 б.]. Телефильм тамашачыларны «шәхесе үзе яшәгән дәвердән аерылгысыз булган» Г. Тукайның язмышы турында уйланырга этәрә. Рецензент шагыйрьнең этисе Мөхәммәтгариф образын тудырганда, сценарий авторының мөстәкыйльлегенә, әнисе Бибимәмдүдә образын тудырганда, психологик сурәтнең тирәнлегенә игътибар иттерә. Ә. Зарипов фильмда татарларның бәйрәм һәм йола мәдәниятен тасвирлауга зур игътибар бирә, мәдрәсәдә уку тәртибе, аның көнкүреше белән таныштыра, боларның исә, үз чиратында, мәдәни-агарту бурычы да зур [29, 16 б.].

Ә. Зариповның архивында Г. Ахуновның «Идел кызы» романын төшерү өчен язган ышаныч кәгазе сакланган [30]. Түбән Камада яшәгән Нурулла Гаптуллин үзенең хатында Свердловск киностудиясендә төшерелгән «Истәлек өчен Гыйлемханга» телефильмы белән «Хәзинә» телефильмын чагыштырып, анализ ясый. Телетамашачы татар телефильмының фәлсәфи тирәнлегенә соклана. Ул Татарстанның табигать күренешләре (Идел, Зөя, Нократ, Мишә елгаларының тугайлары) киләчәктә дә бик күп фильмнарны бизәр дигән өметен белдерә. Н. Гаптуллин фильмның музыкаль бизәлешен дә югары бәяли. Ә. Зарипов фильмны төшергәндә, җырчы Ренат Ибраһимовны чакырган була [31].

ТАССРның Телевизион һәм радиотапшырулар комитеты заказы буенча Ә. Зарипов 1984

елда А. М. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән...» повесте мотивлары буенча телеспектакль төшерә. Премьерадан соң матбугатта кызу бәхәсләр кабынып китә [32]. А. М. Гыйләҗев укучыларыннан һәм тамашачылардан ике йөзгә якын хат ала. Язучы әлеге бәхәсләргә махсус телетапшыруда нокта куя. А. М. Гыйләҗев Бибинур тарихының укучыларда һәм тамашачыларда шундый зур кызыксыну уятуына ихластан шатлана. Шулу к вакытта ул тамашачыларның ялгыз картлык проблемасын гына күрүләренә борчылу да белдерә. Ә. Зарипов Бибинурны авыл кешеләренең кибеттәге гайбәт, имеш-мимешләре көзгесендә күрсәтә, бу исә автор әйтәсе килгән фикерне ярлыландыруга китерә. Спектакльдә баш геройның тарихы авылдашларының – шаһитларның кеше йөрәгендә игелек нуры сүнсә, нәрсә булуы турындагы хоры каймасында бирелә.

Кояш калкыр да батар,
Батар да калкыр,
Мәңге нур чәчәр!

Ә менә кеше күңелендә
Кояш батса –
Җир ничек яшәр?! [33, 4].

Б. Мөхәммәтшин, М. Хәбетдинова, А. Хәбетдинов билгеләгәнчә, «телеспектакльдә бер вакыттан икенче вакытка күчерү өчен героиняны «киендерү» алымы бик уңышлы кулланылган. Ә. Зариповның телеспектаклендә пространство чишелеше театраль шартлылыкка омтыла. Биредә без тормыш чынбарлыгын ничек бар, шулай кабатларга тырышуны күрмибез. Ә Зарипов пространствода полифонияле мохит булдырырга омтыла, ул мохитнең һәркайсында мәгълүмат яңа бер ягы белән ачыла, ул геройларның тормышыннан берәр яңа сәхифә ачып җибәрә, аларның әйләнә-тирәдәгеләр белән үзара мөнәсәбәтләренең характерына ача». ([34]). Чәчмә әсәрне драматик текстка үзгәрткәндә, сценарий авторы А. Гыйләҗев персонажларының сөйләмен индивидуальләштерә алмаган. Бу исә тамашачыларда канәгатьсезлек тудырган.

Апас районы Деваш авылыннан Наилә Сафина үзенең хатында режиссёрны телефильмга «ясалмалылык» алып керүе өчен тәнкыйтьли: «Ә бит Аяз абый повестьта берниндиясалмалылык та язмаган, ул тормышның үзен язган» [35]. Мәсәлән, Казаннан Хәмидуллинаның тәнкыйть уты, телеспектакль турында фикер алышканда, актёрларның сөйләм культурасына юнәлә: «Нигә спектакльдәге рольләрне зур уңыш белән башкаручы артистлар телевидениедән үз рольләре, геройлары турында чиста татар телендә матур итеп, тамашачыга үз фикерләрен җиткерә алмыйлар?» [36].

Ә. Зарипов 1992 елда төшергән «Галиябану» телеспектакле матбугатта кайнар бәхәсләр уятып җибәрә. Р. Аймәт фикеренчә, телеспектакльнең яңачалыгы шунда ки, ул Актаныш һәм Кайбыч районнары авылларында ачык һавада төшерелә [37]. Тамашачылар режиссёрны яшьләрнең кичке уеннары атмосферасын тудыру өчен чакырылган үзешчән «Агыйдел» ансамбле катнашлыгындагы сәхнәләрне каты тәнкыйтьләп чыгалар. Тамашачылар фикеренчә, өлкән яшьтәге артистлар мәхәббәт тарихы көзгесендә ямьсез күренә [38], [39]. Тамашачыларның уртак фикеренчә, Галиябану роле Лидия Әхмәтованың иҗади уңышсызлыгы булып тора. Телеспектакльне шулай ук халык җырларын халык рухында башкара алмаган профессиональ җырчылар да боза.

Ә. Зарипов Ә. Еники белән берлектә әдипнең «Төнге тамчылар», «Гөләндәм туташ хатирәсе» әсәрләре буенча төшерелгән телефильмнарын бик җылы хатирәлрә белән искә ала [40]. Ә. Зариповның архивында Ильдар Юзеевның «Бер генә сәгатькә» повестена карата язылган шигъри рефлексиясе – шигыре дә саклана:

Бер генә сәгатькә...

Ул килгәнче егет китеп барган...
Күрешәлмәү – нинди авыр бит...
Аңла инде сөйгән ярлар хәлен...
Тукта, поезд, китмә, сабыр ит!
    Китте... китте сугыш кырларына,
    Анда – атыш, вәхшәт, үлештер.
    Бәлки, соңгы тапкыр күрүемдер...
    Тукта, поезд, зинһар, күрештер!
Ник кызгандың, язмыш, бу гүзәлдән
Тик бер генә сәгать вакытны?
Тукта, поезд, бары бер сәгатькә
Озынайтчы авыр бәхетне!
    Туктатырга вакыт мизгелләрен
    Юкмыни соң тик бер сәбәп тә?
    Тукта, поезд, аны бәхетле ит
    Күпкә түгел, тик бер сәгатькә... [41]

Т. Галиуллинның «Бомба», «Дәгъва» хикәяләре мотивлары буенча төшерелгән «Олыларда бала-чага уены» телеспектакленең сатирик табигатен анализлап, әдәбият белгече

Н. Ханзафаров режиссёрның автор фикерен гәүдәләндерү өчен фарс алымнарын куллануын уңышлы дип бәяли [42].

«Намус» спектакле бик күп тамашачыларның йөрәгенә май булып ята, һәм алар сәхнәдәге сюжетның тормышчанлыгын ассызыклап, редакциягә дистәләгән шуңа охшаш тарихларны язып җибәрәләр (мәсәлән, Аксубай районыннан Мәгъмүзә Батыршинаның хатын карагыз [43] ).

Шәриф Хөсәенов әсәре буенча куелган «Безнең подъезд төбендә» спектакленә бик күп хатлар килгән. Хат авторлары заманның әхлакый проблемалары турында үзләренең борчылулары белән бүлешә [44]; [45]. Казаннан Суфия Галимова телеспектакльне караганда, туганнары белән чын мәгънәсендә тетрәнү кичерүләре турында яза: «Безнең телевидениедә әлегә кадәр моңа охшашлы спектакльләрнең булганы юк иде әле. Бик зур рәхмәт сезгә! Үзгәртеп корулар турында сөйләшәбез икән, менә шулай эшләргә кирәк. Спектакль халыкны йокыдан уятырга ярдәм итәр... » [46]. Журналист Кояш Тимбикованың да язмасы шушындый рухта язылган [47].

Әхтәм Зариповның архивында тамашачылар хатлары белән танышканда, без телеспектакльләрне рус теленә тәрҗемәдә кабатлап күрсәтүләрен үтенеп язган хатларның күбәюенә игътибар иттек. Бу татар мохитендәге ассимиляция процессларының бер чагылышы. Моннан тыш, без 1990 елларга хатларда көндәлек, гади тарихларның күбәюенә игътибар иттек, күрәсең, дистәләрчә елларга сузылган идеологик диктаттан соң, кешеләрнең хис-кичерешләре белән уртаклашу ихтыяҗы шул рәвешле чагылыш тапкан.

Татар телетеатры тарихында режиссёр Идмас Үтәгәновның иҗаты аерым бер урын алып тора. 1960 елда ул ГИТИСның театр белгечлеге факультетын тәмамлап, Казанга кайта. Казан телевидение студиясендә беренче чорда режиссёрлар җитмәү сәбәпле, аңа төрле редакцияләрдә: пропаганда, авыл хуҗалыгы, сәнәгать, «Яңалыклар», балалар һәм яшьләр редакцияләрендә режиссёр булып эшләргә туры килә. И. Үтәгәнов Ә. Хәсәновның «Алмагачым минем, әнием», «Әти диясем килә» дигән ике кисәкле оригиналь әсәрен экранга күчерә.

1989 елда татар телендәге беренче телемюзиклны – «Мырау батыр»ны иҗат итүе белән таныла. «Мырау батыр» Нәкый Исәнбәтнең шул исемдәге әсәре буенча төшерелә. Сценарийны режиссёр Индус Сирматов белән бергә яза. Телемюзиклны төшерүдә Казанның бөтен театрлары да катнаша. ТАССРның телерадиокомпаниясе иҗади командага вакытны бик аз бирә: көнгә бер серия төшерергә кирәк була. Шул ук вакытта студиягә килгәнче, артистлар ул көнне нәрсә уйныйсыларын белмиләр әле – сценарий белән туп-туры шунда танышалар, вокал яздыру да шундый ук шартларда бара (композиторы – Рәшит Абдуллин). Мюзиклда «Бәхетле балачак» хореографик ансамбле балалары катнаша (сән. җит. Светлана Ишкузина).

«Мырау батыр» татар тамашачылары өчен зур вакыйга була. Халык һәрбер серияне түземсезләнеп көтеп ала, коллектив караулар оештыралар, ничек тәмамланыр икән дип, фикер алышулар уздыралар. Премьерадан соң көн саен дистәләрчә хатлар килә башлый. Өлкәннәр балаларның, уйнаганда, Мырау-батыр булыр өчен сугышулары турында яза [48].

И. Үтәгәновның икенче эше «Тукай» студиясендә шулай ук балалар өчен төшерелә. Ул өч серияле «Азат Мәргән» телефильмы була.

Телеспектакльләр төшерү бу эшне финанслау туктатылу сәбәпле юкка чыга.

Режиссёр Гөлсем Белялова Ә. Хәсәновның «Судан табылган хат», «Урман әкияте», «Октябрь кызы» дип аталган сценарийларын тормышка ашырганын искә алсак, балалар өчен тапшырулар редакциясе үз алдына куйган бурычларын бу өлкәдә дә җиренә җиткереп үтәгән дип танырга кала, чөнки спектакльләрдә тәгаен мисаллар нигезендә рухи-әхлакый, иҗтимагый-сәяси, дустанә, толерантлы тәрбия проблемалары чишелә һәм бу эш җәмгыятьтә тиешле бәясен ала. СССРның төп мәгълүмат чарасы булган «Правда» газетасының бер санында чыккан баш мәкаләдә Казан телевидениесе эшчәнлеге уңай бәяләнә, студия хезмәткәрләренең Дәүләт телерадиосы һәм СССРның үзәк мәдәният профсоюзы Үзәк комитетының мактау грамоталары белән бүләкләнүе дә әнә шул хакта сөйли. Икенче яктан караганда, Казан телевизион драматургиясе дигән өр-яңа жанр үз урынын тапкан дигән фикер раслана.

**Нәтиҗәләр**

Тикшерүгә нәтиҗә ясап, без 1970–1990 елларда төшерелгән татар спектакльләре татар мәдниятен популярлаштыруның нәтиҗәле формасы булган дип саныйбыз. Татар

режиссёрлары төрле жанрларда үзенчәлекле телеспектакльләр төшергән. Телеспектакльнең әдәби нигезе булып, XX гасыр татар язучыларының иң яхшы әсәрләре файдаланылган. Массакүләм тамашачының кызыксынуы торгынлык һәм үзгәртеп кору елларында телевидениенең ял итү формасына әверелүе белән аңлатыла. Халык арасында театр артистлары зур популярлык казана. Күпчелек тамашачыларның, театрларның республиканың эре шәһәрләрендә генә урнашуы сәбәпле, спектакльләргә йөрү мөмкинлеге булмый. Әдәби-драматик редакциягә килгән хатларның саны йөзләр белән исәпләнә. Хат авторлары караган телеспектакльләре турында тәэссоратлары белән генә бүлешеп калмый, театрның һәм телевидениенең киләчәге турында фикер йөртә, үзләренең тормыш хәлләре турында да яза. Хат язучыларның әдәби һәм мәдәни яктан күп белүе сөендерә. Яраткан телеспектакльләрен кабатлап күрсәтүне сорап язган хатлар бик күп.

## Йомгак

Татар телетеатры тарихы алга таба да өйрәнүне һәм системага салуны таләп итә. Безнең мәкалә кереш мәкалә сыйфатларына ия. Бу әле татар мәдәниятенең шушы өлкәсен тикшеренүдә беренче адымнар гына.

**Рәхмәт сүзләре:** мәкалә авторлары Әнәс Хәсәновка, Әхтәм Зариповка шәхси архивларыннан татар телевидениесе тарихына караган материаллар белән уртаклашуы өчен рәхмәтләрен белдерә.

**Әдәбият**

1. Век кино в Казани. Сорок лет Казанской студии кинохроники // Казань. 2001. № 9–10.

2. Говорит Казань! – Казан сөйли!: исторические документы, фотоматериалы, воспоминания, беседы и статьи к 80-летию радио Татарстана / Фил. Федерального гос. унитарного предприятия ВГТРК, Гос. телерадиовещательная компания «Татарстан»; авт.-сост.: Заудат Дарзаман, Насим Акмал. Казань: Идел-Пресс, 2008. 294 с.

3. *Алексеева Е. П.* Казань. Кинематограф. Из века в век. (1897–2014 гг.). Казань, 2016. 428 с.

4. *Алексеева Е. П.* Союз кинематографистов Республики Татарстан: 25 лет. Казань, 2007. 64 с.

5. *Галимзянова А. Т.* Становление и развитие Казанской студии кинохроники (1961–1991 гг.) Казань: Издательство Казанского университета, 2020. 168 с.

6. *Даутова Р. В.* Партийно-государственная политика в области средств массовой информации автономных республик Поволжья и Приуралья (1953– 1964 гг.): дис. ... докт. истор. наук: 07.00.02. Казань, 2011. 402 с.

7. *Даутова Р. В.* Становление развитие телевидения Татарстана (вторая половина 1950-х – 1985 гг.). Казань: изд-во Казанского университета, 2008. 191 с.

8. *Даутова Р. В.* Телевидение Татарстана: от прошлого к настоящему Казань: Новое знание, 2010. – 278 с.

9. *Даутова Р. В.* Телевизионное вещание // Татарская энциклопедия в 6 т. Т. 5. С. 610–611.

10. *Лапин С. Г.* Телевидение // Большая советская энциклопедия, в 30 т. Т. 25. М.: Сов. энц-я, 1976. С.386.

11. Основы фильмопроизводства / В. С. Богатова. М.: Искусство, 1975. С. 180. 448 с.

12. *Сидорова Г. П.* Русский театр для массового зрителя в советской культуре: фильм-спектакль и телеспектакль // Ярославский педагогический вестник. 2019. № 6 (111). С. 213–220.

13. *Липков А. И.* Проблемы телефильма-спектакля // Поэтика телевизионного театра. М.: Искусство, 1979. С. 95–114.

14. *Юренев Р. Н.* Фильмы-спектакли // Вопросы киноискусства: Сборник статей / Отв. ред. Ю. С. Калашников; Акад. наук СССР. Ин-т истории искусств. М.: Искусство, 1955. С. 412–427.

15. Откровения телевидения / составитель и редактор А. П. Свободин. М.: Искусство, 1976. 44 с. URL: http://indbooks.in/mirror8.ru/?page_id=144955 (дата обращения: 31.05.2022).

16. *Сакаева Г. Р.* Из жизни режиссера Р. С. Сакаева // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2010. №. 1–2. С. 268–272.

17. «Вернувшиеся». Премьера на ТВ // Вечерняя Казань. 22 мая 1981 года.

18. *Галиуллина М.* Кадр артындагы иң кадерле кешебез // Мәдәни җомга. 2020. № 45. 13 ноября. Б. 12–13.

19. Ә. Зарипов шәхси архивы: «Йолдызлар җитә һәркемгә». Туфан Миңнуллин рецензиясе. Кулъязма. 1 бит. Пагинациясез. 10.10. 1976.

20. Ә. Зарипов шәхси архивы: Илдус Әхмәтҗановның хатирәләре. Кулъязма. Ә. Зарипов тарафыннан язып алынган. 1 б.

21. *Нуруллин И.* Тукай Петербургта: драма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 93 б.

22. *Нуруллин И.* Тукай турында хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 135 б.

23. *Ишмөхәммәтов З. А.* Тукай атеизмы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 70 б.

24. Ә. Зарипов шәхси архивы: «Тукай». Документаль әсәр. Авторы Әхтәм Зарипов. Сибгать Хәким рецензиясе. Машинкада басылган. Казан. 2 б. 12.03.1986.

25. Ә. Зарипов шәхси архивы: укытучы Ф. И. Гафурованың хаты. Украина. 07.07. 1986. Кулъязма. 1 б. Рус телендә.

26. Ә. Зарипов шәхси архивы: Сәет һәм Бикә Шәкүроваларның хаты. Казан. 10.07.1986. Кульязма. 1 б.

27. Ә. Зарипов шәхси архивы: Габдеррәшид Тукатаровның хаты. Кульязма. 1 б. 13.07. Елы күрсәтелмәгән.

28. *Кумысников Х.* Прогулка с поэтом // Республика Татарстан. 1996. 25 апреля.

29. *Әхмәтьянов Р.* Шагыйрьнең сабый чагына сәяхәттән соң... // Мәдәни җомга. 1996. 13 декабрь. Б. 14,16.

30. Ә. Зарипов шәхси архивы: Доверенность Гарифа Ахунова на исценировку романа «Дочь Волги» Ахтямом Зариповым. Казань. 03.10.1987. Рукопись. 1 с.

31. Ә. Зарипов шәхси архивы: Нурулла Гаптуллинның хаты. Нижнекамск. Кульязма. 1 б. Датасы күрсәтелмәген.

32. *Хөснимәрдәнов М.* «Бибинурга сүз әйтмәгез...» (Зәнгәр экран янында) // Социалистик Татарстан. – 1985. – 13 гыйнварь.

33. Ә. Зарипов шәхси архивы: «Җомга көн, кич белән...» (А. Гыйләҗев повесте мотивлары буенча драматик вариацияләр) Машинопись. 70 б. 1984 ел.

34. Muhametshin B, Khabutdinova M, Khabutdinov A.J., The ideological and artistic originality in the dramatization of the story ««on friday night» (1972–1979) by Gilyazova A. M., made by A. Zaripov //Astra Salvensis. – 2017. – Vol.5, Is.10. – P.191–198.

35. Ә. Зарипов шәхси архивы: Апас районы Дәваш авылы Наиля Сафинаның хаты. Кульязма. 1 б. Датасы күрсәтелмәген.

36. Ә. Зарипов шәхси архивы: Казаннан Хәмидуллина хаты. Аксубай. Кульязма. Датасы күрсәтелмәгән.

37. *Аймет Р.* «Галиябану» кайткан // Шәһри Казан. 1994. 28 мая.

38. *Галиев Ә.* «Галиябану»мы соң бу? // Ватаным Татарстан. 1992. №14.8 б.

39. Ә. Зарипов шәхси архивы: Әклимә Галиуллинаның хаты. Кульязма. 1 б. Датасы күрсәтелмәген.

40. Градус күтәрерлек әсәрләр кирәк / Ә. Зарипов белән Г. Гыймадова әңг. // Ватаным Татарстан. 2015. № 161 23 октябрь. Б. 6.

41. Ә. Зарипов шәхси архивы: Илдар Юзеев «Бер генә сәгатькә». Машинкада басылган. 1 б.

42. Ханзафаров Н. Сатира «тешен күрсәтә» // Мәдәни җомга. 1992. №18. 8 б.

43. Ә. Зарипов шәхси архивы: Мәгзүмә Батыршинаның хаты. Аксубай. Кульязма. Датасы күрсәтелмәгән.

44. Ә. Зарипов шәхси архивы: Д. К. Хәкимованың, А. А. Зяббарованың хаты. Кульязма. Казан. 07.07. 1986. 1 б.

45. Ә. Зарипов шәхси архивы: Нажибә Ардеханованың хаты. Кульязма. Датасы күрсәтелмәгән.

46. Ә. Зарипов шәхси архивы: Казаннан Сүфиә Галимованың хаты. Кульязма. Датасы күрсәтелмәгән.

47. Ә. Зарипов шәхси архивы: Кояш Тимбикованың хаты. Кульязма. 1 б. Датасы күрсәтелмәгән.

48. *Юсупов С.* Устная история. Телемюзикл «Мырау Батыр» как незамеченная психоделическая революция в ТАССР // Устная история. Телемюзикл «Мырау Батыр» как незамеченная психоделическая революция в ТАССР // Инде (inde.io) (дата обращения: 02.02.2022).

**Appendix No. 1/Приложение №1**

## THE LIST OF TELEVISION PLAYS DIRECTED BY AKHTYAM ZARIPOV AT THE STATE TV AND RADIO BROADCASTING COMPANY IN 1972-1995

## 1972-1995 ЕЛЛАРДА ӘХТӘМ ЗАРИПОВ ТАРАФЫННА ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯСЕНДӘ ТӨШЕРЕЛГӘН ТЕЛЕСПЕКТАКЛЬЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

| № | Телеспектакльнең исеме | Әдәби нигезе | Озынлыгы, сериядә |
|---|---|---|---|
| 1 | «Ата хакы» | Салих Батталның «8 нче көн» повесте буенча | 1 |
| 2 | «Көйсез кияү» | Туфан Миңнуллинның беренче китабы буенча | 1 |
| 3 | «Милициям» | Рәйсә Ишморатова әсәре буенча | 1 |
| 4 | «Чоңгыллар» | Мөсәгыйт Хәбибуллин романы буенча | 5 |
| 5 | «Җомга көн, кич белән...» | Аяз Гыйләҗев повесте буенча | 3 |
| 6 | «Әтәч менгән читәнгә» | Аяз Гыйләҗев повесте буенча | 1 |
| 7 | «Ут һәм су» | Әхсән Баянов әсәре буенча | 1 |
| 8 | «Йолдызлар һәркемгә җитә» | Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте» буенча | 1 |
| 9 | «Зәңгәр кыңгыраулар» | Әхсән Баяновның әсәре буенча | 1 |
| 10 | «Саф күңел» | Мирсәй Әмир әсәре буенча | 3 |
| 11 | «Язмыш шуклыгы» | Фатих Хөсни әсәре буенча | 2 |
| 12 | «Ике буйдак» | Атилла Расих | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | әсәре буенча | |
| 13 | «Ямашев» | Атилла Расих әсәре буенча | 1 |
| 14 | «Солдат Швейк» | Ярослав Гашек әсәре буенч. | 1 |
| 15 | «Кавказ әсире» | А. Пушкин әсәре буенча. (Лермонтов турында) | 1 |
| 16 | «Вөҗдан тотка-ны» | В. Жуковский әсәре буенча (А.С. Пушкин турында) | 2 |
| 17 | «Һәйкәл» | А. Довженко әсәре буенча | 1 |
| 18 | «Олыларга бала-чагы уены» | | 2 |
| 19 | «Кияү» | Тәлгат Галиуллин повесте буенча | 3 |
| 20 | «Нотык» | Шәриф Камал әсәре буенча | 2 |
| 21 | «Уяну» | Шәриф Камал әсәре буенча | 1 |
| 22 | «Хаҗи әфәнде өйләнә» | Шәриф Камал әсәре буенча | 3 |
| 23 | «Генеральная уборка» | Шәриф Хөсәенов әсәре буеча | 2 |
| 24 | «Безнең подъезд төбендә» | Шәриф Хөсәенов әсәре буеча | 2 |
| 25 | «Откуда ты, Жан?» | Шамил Рәкыйпов әсәре буенча | 1 |
| 26 | «Шәфкать» | Мәдинә Маликова әсәре буенча | 3 |
| 27 | «Егетлеккә бер адым» | Мәдинә Маликова әсәре буенча | 2 |
| 28 | «Ике әби бәрәңге ала» | Газиз Мөхәммәтшин әсәрләре буенча | 1 |
| 29 | «Сагыш» | | 1 |
| 30 | «Галиябану» | Мирхәйдәр Фәйзи әсәре буенча | 3 |
| 31 | «Габбас хәзрәт» | Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы буенча | 5 |
| 32 | «Яз сулышы» | Ибраһим Нуруллин хикәяләре буенча | 1 |
| 33 | “Тукай Петербургта» | Ибраһим Нуруллин әсәре буенча | 1 |
| 34 | «Каргышлы балачак» | Гариф Ахунов һәм Әхтәм Зарипов сценарие | 8 |
| 35 | «Тукай» | Әхтәм Зарипов сценарие | 5 |
| 36 | «Капка» | Әхтәм Зарипов сценарие | 3 |
| 37 | «Килен-киленне сынар» | Әхтәм Зарипов сценарие | 1 |
| 38 | «Үзеңеке үзәктә» | Әхтәм Зарипов сценарие | 1 |
| 39 | «Урын» | Әхтәм Зарипов сценарие | 1 |
| 40 | «Уен» | Әхтәм Зарипов сценарие | 1 |
| 41 | «Соңгы сөю» | Әхәт Гаффар буенча | 1 |
| 42 | «Истәлек өчен Гыйлемханга» | Ринат Мөхәммәдиев әсәре буенча | 1 |

# ТАТАРСКИЙ ТЕЛЕТЕАТР В ЗЕРКАЛЕ ОБЩЕСТВЕННОГО МНЕНИЯ[1]

**Гульуся Габдрашитовна Аксой,**
Бартынский университет,
Турция, Бартин, Факультет Агаджи, 54,
gaksoy@bartin.edu.tr.

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

В статье систематизирован материал по истории татарского телетеатра. Материалом исследования послужили телеспектакли, созданные татарскими режиссерами Гали Хусаиновым, Ринатом Сакаевым, Ахтямом Зариповым, Идмасом Утягановым, Гульсум Биляловой, а также рецензии и письма телезрителей. Доказано, что татарские телеспектакли и телефильмы в 1970–1990 гг. являлись эффективной формой популяризации татарской культуры. История телетеатра рассмотрена в зеркале переписки телезрителей с редакцией литературно-драматических передач Казанской телестудии.

**Ключевые слова:** татарская культура, татарское телевидение, татарский театр, телеспектакль, телефильм, письма читателей

[1] Материал по степени изученности истории российского и татарского телетеатра обобщен Аксой Г.Б., анализ архивных материалов в личном архиве режиссера Ахтяма Зарипова осуществлен Хабутдиновой М.М.